**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ V ЧАКЫРЫЛЫШ X СЕССИЯСЕ**

**КАРАР № 47**

Мөслим авылы 30 август 2026 ел

**«Мөслим муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль район Советының 2021 елның 27 октябрендәге 60 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм „гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында“ Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлешенең 29 пунктындагы „д“ пунктчасының үз көчен югалтуын тану хакында» 2026 елның 20 февралендәге 23-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, аның нигезендә 2026 елның 1 сентябреннән муниципаль торак контроле турындагы нормалар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрдән төшереп калдырылалар, ә вәкаләтләр Россия Федерациясе субъектлары дәрәҗәсенә тапшырылалар, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының «Мөслим муниципаль районында муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 октябрендәге 60 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р.Хуҗин